**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 592

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 6 сентябрь, 642 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 6 сентябрь, 642 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Шартнамә шартларын үтәүне тикшерүдә тоту максатларында Оешма:

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче икенче айның 15 көненнән соңга калмыйча һәм узган салым чорыннан соң килүче елның 10 апреленнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә 6 нчы һәм 7 нче кушымталар нигезендә хисап мәгълүматын Вәкаләтле органга тапшыра;

ел саен, узган салым чорыннан соң килүче елның 10 апреленнән дә соңга калмыйча, Оешма җитәкчесе һәм тикшерүне башкарган салым органының вазыйфаи заты имзалаган, салым законнарында билгеләнгән рәвештә инвестицион салым кредиты буенча өстәп исәпләнгән һәм түләнгән процентларны (инвестицион салым кредиты бирелгән салымнар буенча) салым органы белән тикшерү актын Вәкаләтле органга тапшыра;

инвестицион салым кредиты түләнә башлаган көнгә кадәр 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, Оешма җитәкчесе һәм тикшерүне башкарган салым органының вазыйфаи заты имзалаган, салым законнарында билгеләнгән нигездә Оешмага бирелгән инвестицион салым кредиты суммасын һәм аның буенча өстәп исәпләнгән һәм түләнгән процентларны салым органы белән тикшерү актын Вәкаләтле органга тапшыра,

ел саен, 1 майга кадәр, әлеге Тәртипкә 8 нче кушымта нигезендә форма буенча эшчәнлекнең төп күрсәткечләре турында һәм әлеге Тәртипкә 9 нчы кушымта нигезендә форма буенча инвестицион салым кредитын файдалану турында мәгълүматны Вәкаләтле органга тапшыра;

Оешма эшчәнлегенең төп күрсәткечләре шактый үзгәрүгә китерә торган шартлар турында Вәкаләтле органга мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган түбәндәге вазыйфаларны башкара:

бирелгән инвестицион салым кредитлары реестрын алып бара;

Оешма эшчәнлегенең төп күрсәткечләре үтәлешен һәм Оешманың инвестицион салым кредитын үз вакытында каплавын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

кимендә ярты елга 1 тапкыр әлеге Тәртипкә 10 нчы кушымта нигезендә форма буенча гамәлдәге законнар нигезендә Оешмага бирелгән инвестицион салым кредитының икътисади, социаль һәм бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпләүне гамәлгә ашыра;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 30 көненә кадәр әлеге Тәртипкә 11 нче кушымта нигезендә форма буенча Оешмага бирелгән һәм түләнгән инвестицион салым кредиты суммалары турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына мәгълүмат юллый;

Шартнамәгә үзгәрешләр кертү зарурлыгы булганда яки Шартнамәне берьяклы өзү өчен нигезләр булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Шартнамәгә өстәмә килешү төзү яки төзелгән Шартнамәнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул итә һәм аны почта аша белдерү кәгазе булган заказлы хат белән Оешмага җибәрә. Мондый карарның күчермәсе Оешманың салым исәбенә куелу урыны буенча салым органына җибәрелә.»;

Тәртипкә яңа 6 нчы һәм 7 нче кушымталар өстәргә (теркәләләр);

Тәртипкә 6 – 9 нчы кушымталарны туры килү буенча Тәртипкә 8 – 11 нче кушымталар дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\592.docx